**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 7 нче сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сораулары**

**Хөрмәтле олимпиадада катнашучы!** Сезгә олимпиаданың алты биремен эшләргә кирәк булачак. Биремнәрне үтәү вакыты – 150 минут. Биремнәр шушы бланкларда эшләнә.
Максималь балл – **40**. Уңышлар!

**1. Татар халык җырларының кайсы төре турында сүз баруын языгыз. (2 балл)**

- алар бию вакытында, күңел ачканда җырлап яки тиз ритм белән әйтелә;
- мондый җырларның бер өлешендә дустыңнан яратып көлү, аны үчекләү, шаяру яки аның билгеле бер сыйфатын мактау чагылыш таба;
- элек алар үзенә күрә уен коралы, гармун вазифасын да үтәгән.

**Җавап**: такмаклар

**2. Татарстан гимнының авторларын атагыз. (1 балл)**

а) Салих Сәйдәшев, Рамазан Байтимеров

ә) Салих Сәйдәшев, Равил Фәйзуллин

б) Рөстәм Яхин, Рамазан Байтимеров

**Җавап:**

б) Рөстәм Яхин, Рамазан Байтимеров

**3. Сорауларга җавап бирегез.**



**1) Портреттагы әдипнең исемен языгыз. (1 балл)**

**Җавап:** Шәүкәт Галиев

**2) Ул кайда туган? Дөрес җавапны билгеләгез. (2 балл)**

а) Татарстанның хәзерге Яшел Үзән районы Югары Шырдан авылы

ә) Башкортстанның  Бишбүләк районы Ает авылы

б) Татарстанның Апас районы Олы Бакырчы авылы

в) Мордовия Республикасы Пешлә авылы

**Җавап:** б) Татарстанның Апас районы Олы Бакырчы авылы

**3. Әлеге әдипнең әсәрләре генә кергән рәтне күрсәтегез. (2 балл)**

а) «Шәвәли», «Пәрәмәч», «Матурлык минем белән», «Һәркем әйтә дөресен».

ә) «Шәвәли», «Пәрәмәч», «Атлап чыктым Иделне», «Тагын бер “рәхмәт”».

б) «Шәвәли», «Пәрәмәч», «Кызыл ромашка», «Һәркем әйтә дөресен».

в) «Шәвәли», «Пәрәмәч», «Тагын бер “рәхмәт”», «Сез иң гүзәл кеше икәнсез».

**Җавап:** ә) «Шәвәли», «Пәрәмәч», «Атлап чыктым Иделне», «Тагын бер “рәхмәт”».

**4. Бирелгән сүзләр рәте ярдәмендә әсәрләрнең исемен, авторын билгеләгез. (6 балл)**

а) Ай, йолдызлар, күк, Чуртан, Айсылу, тап.

**Җавап:** Ф. Яруллин “Зәңгәр күлдә Ай коена”

ә) Мәгарә, кимия, симия, ихфа, Мисыр, хәлвә, патша кызы, казый.

**Җавап**: К. Насыйри “Әбүгалисина”

б) Колын, чабышкы аты, Сабан туе, мәйдан, ат чабышы, Ялгыз каен, камчы.

**Җавап:** Г. Ибраһимов “Алмачуар”

**5. а) Хикәядән өзек укыгыз.**

...Ахшам үтте. Буранның котыруына карамыйча, капкадан йөри иделәр... Хатыннар берсе килеп кергәндә, икенчесе бик кайгылы кыяфәттә чыгып бара һәм күңелсез генә берәр сүз катыша иделәр...

Тәрәзә янында яткан сары эт, зур һәм кара күзләрен сөзеп, килгәнне каршы ала, киткәнне моңлы күзләре белән озата иде. Ул гүя кайгылы иде... Аның сөйгән тәрбиячесе – хуҗа хатын – бу кич инде үлемнең куркынычлы тырнаклары арасында сугыла иде...

Аның яме киткән, төсе балавыз кебек саргайган, күзләре төпкә баткан, кул һәм аягы салкын, күкрәге бер кабарып, бер төшеп, авыр-авыр сулый. Бичара хатынның өлеше бетеп килә иде...

Илле ел тәнен, уен идарә иткән җан, үзенең иске тонык тәрәзә кебек күзләреннән кемгәдер актык мәртәбә карап, тынычланып китәсе килә иде. Бичара хатын күзләре белән нидер эзли, нидер юксына, кемнедер күрмичә үләсе килми, торып-торып:

– Килмәдеме?.. – дип сорый иде.

Кызы Фатыйма бертуктамый елый.

**б) Сорауларга җавап бирегез.**

**1) Әсәрнең исеме (2 балл) Җавап:** “Буранда”

**2) Әсәрнең авторы (2 балл) Җавап:** Шәриф Камал

**3) Өзектә сүз кем турында бара? (1 балл) Җавап:** ана турында

**4) Ул нинди хисләр кичерә? Ни өчен? (2 балла) Җавап:** юксыну, өзгәләнү, борчылу. Ул улын көтә.

**5) Өзектән**

- **чагыштыруга мисаллар китерегез (3 балл)**

**Җавап:** эт, гүя кайгылы иде; төсе балавыз кебек саргайган; иске тонык тәрәзә кебек күзләреннән.

- **метафорага мисал табып языгыз (1 балл)**

**Җавап**: үлемнең куркынычлы тырнаклары

**6. Үзегез яратып укыган әдәби әсәрне исемен күрсәтмичә, ләкин аны таныrлык итеп характерлап языгыз. Ахырдан әсәрнең исемен, авторын күрсәтегез. Күләме 8-10 җөмлә. (15 балл)**

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 8 нче сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сораулары**

**Хөрмәтле олимпиадада катнашучы!** Сезгә олимпиаданың алты биремен эшләргә кирәк булачак. Биремнәрне үтәү вакыты – 150 минут. Биремнәр шушы бланкларда эшләнә.
Максималь балл – **40**. Уңышлар!

**1. Лириканың кайсы жанры турында сүз баруын языгыз. (2 балл)**

- ул тормыш-яшәешкә кагылышлы уйланулар, яшәү кануннарын бәяли;
- мәхәббәткә, Туган илгә, якыннарга, табигатькә мөнәсәбәтле хис-кичерешләр яшәеш, галәм, яшәү мәгънәсе хакындагы уйлануларга тоташа;
- бу жанрдагы шигъри әсәрләрдә хис-кичерешкә караганда фикер әйтү беренче планга чыга.

**Җавап:** фәлсәфи лирика

**2. Роман жанрының төрләре генә кергән төшенчәләр рәтен билгеләгез (2 балл):**


а) тарихи роман, сәяси роман, детектив роман, мәхәббәт романы, импрессионистик роман, фантастик роман.

ә) тарихи роман, хәрби роман, документаль роман, тәнкыйди роман, фантастик роман, мәхәббәт романы.

б) тарихи роман, хәрби роман, документаль роман, детектив роман, фантастик роман, автобиографик роман.

**Җавап:** б) тарихи роман, хәрби роман, документаль роман, детектив роман, фантастик роман, автобиографик роман

**3. Сорауларга җавап бирегез.**



**1) Портреттагы әдипнең исемен языгыз. (1 балл)**

**Җавап:** Хәсән Туфан

**2) Ул кайда туган? Дөрес җавапны билгеләгез. (2 балл)**

а) Татарстанның Апас районы Олы Бакырчы авылы

ә) Тамбов губернасы Сыркыды авылы

б) Татарстанның Арча районы Кушлавыч авылы

в) Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылы

**Җавап:** ә) Тамбов губернасы Сыркыды авылы

**3. Әлеге әдипнең әсәрләре генә кергән рәтне күрсәтегез. (1 балл)**

а) «Кайсыгызның кулы җылы?», «Ромашкалар», «Агыла да болыт агыла», «Гөлләр инде яфрак яралар».

ә) «Кайсыгызның кулы җылы?», «Ромашкалар», «Матурлык минем белән», «Гөлләр инде яфрак яралар».

б) «Кайсыгызның кулы җылы?», «Ромашкалар», «Агыла да болыт агыла», «Мокамай».

в) «Кайсыгызның кулы җылы?», «Ромашкалар», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә», «Гөлләр инде яфрак яралар».

**Җавап:** а) «Кайсыгызның кулы җылы?», «Ромашкалар», «Агыла да болыт агыла», «Гөлләр инде яфрак яралар».

**4. Бирелгән сүзләр рәте ярдәмендә әсәрләрнең исемен, авторын билгеләгез. (6 балл)**

а) Мәгарә, кимия, симия, ихфа, Мисыр, хәлвә, патша кызы, казый.

**Җавап**: К. Насыйри "Әбүгалисина"

ә) җил, бала, елау, буран, юл, ана, Мокай, эт

**Җавап:** Ш.Камал. "Буранда"

б) Колын, чабышкы аты, Сабан туе, мәйдан, ат чабышы, Ялгыз каен, камчы.

**Җавап:** Г. Ибраһимов "Алмачуар"

**5. а) Повестьтан өзекне укыгыз.**

...Әле иртә, бик иртә иде. Уйсуларга, иңкел һәм үзәннәр өстенә күренер-күренмәс юка гына соры пәрдә эленгән. Рәшә дулкыннары гына түгел ул, юк, түгел. Күтәрелергә өлгермәгән иртәнге томанның нибары җиңелчә генә элпәсе. Көн саен шул бер үк Әверлән буеннан, бер үк үзән һәм болыннардан үзсалар да, Гайнанны һәр көнне яңа күренеш, яңа бизәкләр каршы ала иде. Беркөнне кояш офык астыннан кызган утлы тәлинкәдәй кызарып пәйда була. Икенче көнне сыек томан эченнән алсу-сары әфлисун булып күренә. Аннары ул күзгә күренеп саргая, агара да, ниһаять, карап булмастай алтын нурга әверелә. Ерактагы агымсулар, тымызык күлләр үрдән узганда көнгә каршы елмаялар, икенчесендә сөрелеп яткан кырлар уртасында яшькелт-соры салкын пыяладай хәрәкәтсез калалар. Кайчагында очырып алып китәрдәй җил чыга, икенче көнне табигать аны йокымсырап, талыгып кына каршы ала. Бүген исә Ык буйларына иртәдән үк парлы җылы иңгән иде. Картлар әйтмешенчә, орлыкларның тишелеп чыга торган, тишелгәннәренең котырынып үсеп китә торган көннәре, табигатьнең гомумән ишәя, үрчи, яшелләнә, матурлана торган чагы.

**ә) Сорауларга җавап бирегез.**

**1) Әсәрнең исеме (1 балл)**

**Җавап:** Җидегән чишмә

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)**

**Җавап:** Гомәр Бәширов

**б) Өзектә нинди күренеш бирелә? (1 балл). Бу өзектә ул нинди вазифа башкара? (2 балл)**

**Җавап:** табигать күренеше (пейзаж).

**Җавап:** Бу өзектә ул вакыйгаларның барган урынын тасвирлый, вакыйгаларның урынын һәм вакытын күзалларга ярдәм итә, геройның кичерешләрен билгели, кеше һәм табигатьнең аерымсызлыгын таный.

**в) Өзектән**

- **сынландыруга мисал табып языгыз (2 балл)**

**Җавап:** агымсулар, тымызык күлләр үрдән узганда көнгә каршы елмаялар; табигать аны йокымсырап, талыгып кына каршы ала.

- **чагыштыруга мисал китерегез (2 балл)**

**Җавап:** кояш кызган утлы тәлинкәдәй; кырлар сары пыяладай.

- **эпитетка мисаллар табып языгыз (2 балл)**

**Җавап:** ишәя, үрчи, яшелләнә, матурлана торган чак; алтын нур.

**6. Үзегез яратып укыган әдәби әсәрне исемен күрсәтмичә, ләкин аны танырлык итеп характерлап языгыз. Ахырдан әсәрнең исемен, авторын күрсәтегез. Күләме 8-10 җөмлә. (15 балл)**

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 9 нчы сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сораулары**

**Хөрмәтле олимпиадада катнашучы!** Сезгә олимпиаданың җиде биремен эшләргә кирәк булачак. Биремнәрне үтәү вакыты – 180 минут. Биремнәр шушы бланкларда эшләнә.
Максималь балл – **50**. Уңышлар!

**1. Нинди сәнгати алым турында сүз баруын языгыз. (2 балл)**

- ул бер әйбер, образ аша икенче мәгънәне белдерә, ягъни метафорик алыштыруга нигезләнә;
- ул идеяне һәм образны берләштерә;
- аны куллану сәнгатьнең барлык төрләренә дә хас.

**Җавап:** символ

**2. Әдәбият тарихын чорларга бүлгәндә нинди ике төп фактор исәпкә алына? Дөрес җавапны билгеләгез. (1 балл)**

а) иҗтимагый-тарихи шартлар һәм художестволы урын һәм вакыт.


ә) иҗтимагый-тарихи шартлар һәм әдәби барышның билгеле бер чорына хас үзенчәлекләр.

б) иҗтимагый-тарихи шартлар һәм сәяси хәл.

**Җавап:**

ә) иҗтимагый-тарихи шартлар һәм әдәби барышның билгеле бер чорына хас үзенчәлекләр.

**3. Сорауларга җавап бирегез.**



**1) Портреттагы әдипнең исемен языгыз. (1 балл)**

**Җавап:** Фәнис Яруллин

**2) Ул кайда туган? Дөрес җавапны билгеләгез. (2 балл)**

а) Татарстанның хәзерге Зәй районы Биш Субашы авылы

ә) Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылы

б) Татарстанның Баулы районы Кызылъяр авылы

в) Тамбов губернасы Сыркыды авылы

**Җавап:** б) Татарстанның Баулы районы Кызылъяр авылы

**3. Әлеге әдипнең әсәрләре генә кергән рәтне күрсәтегез. (2 балл)**

а) «Җилкәннәр җилдә сынала», «Сез иң гүзәл кеше икәнсез», «Яралы язмышлар», «Туган ягы кирәк кешегә».

ә) «Җилкәннәр җилдә сынала», «Сез иң гүзәл кеше икәнсез», «Матурлык эзлим», «Туган ягы кирәк кешегә».

б) «Җилкәннәр җилдә сынала», «Сез иң гүзәл кеше икәнсез», «Туган ягы кирәк кешегә», «Матурлык минем белән».

в) «Җилкәннәр җилдә сынала», «Сез иң гүзәл кеше икәнсез», «Гомер китабы», «Чәчәкләр моңы».

**Җавап:** а) «Җилкәннәр җилдә сынала», «Сез иң гүзәл кеше икәнсез», «Яралы язмышлар», «Туган ягы кирәк кешегә».

**4. Персонажларны кайсы әсәрдән алынганлыгын билгеләгез. (4 балл)**

1) Зөләйха а) «Йөзек кашы»

2) Суфиян ә) «Кыйссаи Йосыф»

3) Зыя б) «Әйтелмәгән васыять»

4) Вәсилә в) «Яшь йөрәкләр»

**Җавап:** 1) ә; 2) б); 3) в; 4) а.

**5. Бирелгән сүзләр рәте ярдәмендә әсәрләрнең исемен, авторын һәм жанрын билгеләгез. (9 балл)**

а) хат, артист, врач, пристань, Әдрәс, көндәлек

**Җавап:** Г. Кутуй “Тапшырылмаган хатлар”, повесть

ә) җил, бала, елау, буран, юл, ана, Мокай, эт

**Җавап:** Ш. Камал. “Буранда”, хикәя

б) төш, тулган ай, унбер йолдыз, кое, Йагкуб, кол, сарай

**Җавап:** Кол Гали “Кыйссаи Йосыф”, поэма

**6. а) Хикәядән өзекне укыгыз.**

...Һәм вагон стенасына ышкылып кына яуган вак яңгыр аша әкрен-ачык ишетелгән җыр, күктән иңгән ак канатлы фәрештәдәй, егетне ут эчендә яткан җиреннән сак кына күтәреп, каядыр еракка, татлы хыял дөньясына алып менеп китте. Аның хәтта тәне, һавада йөзгәндәй, җиңеләеп калды, акылы ничектер бердән яктырып китте, сизгерлеге искиткеч үткенләште. Җырны инде ул хәзер моң итеп кенә ишетмичә, гаҗәеп ачык сурәтләр тезмәсе итеп тә күрә иде.

...Менә кыз әкрен генә башлап, аннан тавышын күтәрә төшеп, сузып кына җырлый:

Сарман буйлары, ай, киң ялан,

Печәннәре җитәр бер заман шул,

Печәннәре җитәр бер заман...

Һәм егетнең күз алдына үтә ачык булып, әллә кайларга кадәр җәелеп яткан чуп-чуар чәчәкле болын килә. Үлән башларын, чәчәкләрне селкетеп, йомшак кына җил исә, имеш. Каяндыр, тургай сайрауларына кушылып, чалгы янаган тавышлар ишетелә кебек, йомшак җил кибеп яткан покосларның хуш исен китерә кебек, тик егет печән чабучылар ягына нигәдер борылып карый алмый, имеш. Ул да булмый, аның күз алдына бормаланып киткән тар гына болын юлы килә. Хәтта бер мәлгә егет үзе дә ике рәт үлән арасындагы тәгәрмәч эзеннән, җылы туфракка яланаяк баса-баса, китеп бара кебек, ә каршысына киез эшләпә кигән, таяк таянган ак сакаллы бер бабай килә кебек.

**б) Сорауларга җавап бирегез.**

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)**

**Җавап:** “Кем җырлады?”

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)**

**Җавап:** Әмирхан Еники

**б) Өзектә сүз кем турында бара? (1 балл) Җыр образы нинди көчкә ия? (2 балл)**

**Җавап:** Өзектә яралы егетнең саташуы турында сүз бара. Җыр егетне татлы хыял дөньясына алып китә, әдәби герой күңелендә хатирәләр яңарта, матур күренешләрне күз алдына китереп бастыра.

**в) Өзектән**

- **чагыштыруга мисаллар табып языгыз (4 балл)**

**Җавап:** күктән иңгән ак канатлы фәрештәдәй җыр; һавада йөзгәндәй; җылы туфракка яланаяк баса-баса, китеп бара кебек; киез эшләпә кигән, таяк таянган ак сакаллы бер бабай килә кебек.

- **эпитетка мисаллар табып языгыз (5 балл)**

**Җавап:** ут эчендә яткан егет; татлы хыял дөньясы; гаҗәеп ачык сурәтләр тезмәсе; йомшак җил; хуш ис.

**7. Үзегез яратып укыган әдәби әсәрне исемен күрсәтмичә, ләкин аны танырлык итеп характерлап языгыз. Ахырдан әсәрнең исемен, авторын күрсәтегез. Күләме 10-12 җөмлә. (15 балл)**

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 10 нчы сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сораулары**

**Хөрмәтле олимпиадада катнашучы!** Сезгә олимпиаданың җиде биремен эшләргә кирәк булачак. Биремнәрне үтәү вакыты – 180 минут. Биремнәр шушы бланкларда эшләнә.
Максималь балл – **45**. Уңышлар!

**1. Кайсы иҗат методы турында сүз баруын языгыз. (2 балл)**

- ул җәмгыятьне үзгәртеп коруның төп чарасы итеп кешеләрнең аңын үстерү, аларны гыйлемле, һөнәрле һәм югары әхлаклы итүне күрә;
- геройларны уңай һәм тискәрегә кискен аерып бирә;
- геройлар гамәлләренең, язмышларының гаилә тәрбиясенә һәм иҗтимагый мохиткә бәйле булуын билгели.

**Җавап**: мәгърифәтчелек реализмы

**2. Татар әдәбиятының чишмә башы булып саналган әсәрләр авторлары рәтен күрсәтегез (1 балл):**

а) Әхмәд Йүгнәки, Мәүлә Колый, Әхмәд Ясәви.

ә) Әхмәд Йүгнәки, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый.

б) Әхмәд Йүгнәки, Йосыф Баласагунлы, Кол Шәриф.

**Җавап:**

ә) Әхмәд Йүгнәки, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый.

**3. Сорауларга җавап бирегез.**



**1) Портреттагы әдипнең исемен языгыз. (1 балл)**

**Җавап:** Сәгыйть Рәмиев

**2) Ул кайда туган? Дөрес җавапны билгеләгез. (1 балл)**

а) Казан губернасының Чистай өязендәге Яуширмә авылы

ә) Башкортстанның Җилем-Каран авылы

б) Оренбург губернасы Акман (Ибрай) авылы

в) Казан шәһәренең Яңа Бистәсе

**Җавап:** б) Оренбург губернасы Акман (Ибрай) авылы

**3. Әлеге әдип турында дөреслеккә туры килмәгән фактны билгеләгез. (1 балл)**

а) Бу әдипнең иҗатын ике чорга бүлеп өйрәнү кабул ителгән: Җаек чоры һәм Казан чоры.

ә) Ул “Таң вакыты” шигыренең авторы.

б) Аны шагыйрь Дәрдмәнд белән туганлык җепләре бәйли.

в) Ул татар әдәбиятына бунтарь рухлы романтик герой алып килә.

**Җавап:** а) Бу әдипнең иҗатын ике чорга бүлеп өйрәнү кабул ителгән: Җаек чоры һәм Казан чоры.

**4. Хисам Кятиб кайсы чор әдәбияты вәкиле булуын билгеләгез. (1 балл)**

а) Борынгы чор татар әдәбияты.

ә) Алтын Урда чоры әдәбияты.

б) Казан ханлыгы чоры әдәбияты.

в) Торгынлык чоры әдәбияты (XVI гасырның  II яртысы – XVIII гасыр).

**Җавап:** ә) Алтын Урда чоры әдәбияты.

**5. Бирелгән сүзләр рәте ярдәмендә әсәрләрнең исемен, авторын һәм жанрын билгеләгез. (9 балл)**

а) Пәке, йола, шәҗәрә, миләш агачы, Гөлйөзем әби, талак, ике каен.

**Җавап:** Г. Исхакый “Сөннәтче бабай”, повесть

ә) а) Мәгарә, кимия, симия, ихфа, Мисыр, хәлвә, патша кызы, казый.

**Җавап:** К. Насыйри “Әбүгалисина”, повесть

б) Хат, Җил, Ай, наборщик, комсомолка, ана, бала, ирекле сөю.

**Җавап:** Һ. Такташ “Мәхәббәт тәүбәсе”, поэма

**6. Повестьтан өзекне укыгыз.**

...Шулай итеп, көннәрдән бер көнне мин төяндем дә пароходка төшеп киттем. Киң Идел мине үзенең ягымлы кочагына алгач, үземне бөтенләй исерек кеше шикелле хис иттем. Шәһәрдә торганда, рухымны басып торган авырлык кинәт әллә кая очкан, югалган иде. Минем бу вакыттагы халәти рухиямне бары яңа авырудан терелеп, беренче мәртәбә дөньяга чыккан кешенеке белән генә чагыштырырга мөмкин. Беләсезме, андый вакытта кешегә бөтен дөнья яңа булып күренә. Гүяки ул яңа гына туган яисә үлеп яңадан терелгән. Элек игътибар да итмәгән юк кына нәрсәләр дә аңар әллә ничек сөйкемле булып күренәләр; иң гади агачны, койма буенда үскән яшел чирәмне, җирдә яткан ташны, кояш астында үзенең пәрәвезен корып ята торган үрмәкүчне күрү дә аны балалар шикелле сөендерә. Мин бу тойгыны ни дип атарга да белмим инде. Минемчә, аны «тереклек шатлыгы» дип атарга яисә кинәт әллә нинди ильһам буенча тормышның мәгънәсен аңлау дияргә мөмкин.

Ни булса да, мин шат идем, мин бәхетле идем. Идел үзенең тулган, яңа гына яшәреп килә торган ярларында тын гына, мәһабәт кенә ага, мин бер дә уйсыз-нисез генә пароходның борынында утырам, бер ялтыраган киң Идел өстенә, бер зәңгәр һавага күземне салам. Язгы су исе килеп торган Идел җиле минем битемә бәрелә, җиңнәремнән кереп, беләкләремне кытыклый. Мин утырам да җүләр кеше шикелле үз-үземә уйлыйм: «Кара син аны, нинди матурлыклар бар икән дөньяда!» — дим.

**Өзек буенча сорауларга җавап бирегез.**

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)**

**Җавап:** Идел

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)**

**Җавап:** Гали Рәхим

**б) Өзектә әдәби геройның кая баруы тасвирлана? (1 балл)**

**Җавап:** Геройның шәһәрдән табигатьтә яшәү өчен пароходка утырып баруы тасвирлана.

**Герой моңа бәйле нинди хисләр кичерә? (2 балл)**

**Җавап:** җиңеллек, куану, сөенү, соклану, канәгатьләнү.

**в) Өзектән**

- **метафорага мисаллар табып языгыз (2 балл)**

  **Җавап:** тереклек шатлыгы; пароходның борыны.

- **чагыштыруга мисал китерегез (4 балл)**

  **Җавап:** исерек кеше шикелле; яңа авырудан терелеп, беренче мәртәбә дөньяга чыккан кешенеке белән генә чагыштыру; балалар шикелле сөенделәр; җүләр кеше шикелле.

- **эпитетка мисаллар табып языгыз. (3 балл)**

  **Җавап:** ягымлы кочак, сөйкемле нәрсәләр, мәһабәт ага.

**7. Үзегез яратып укыган әдәби әсәрне исемен күрсәтмичә, ләкин аны танырлык итеп характерлап языгыз. Ахырдан әсәрнең исемен, авторын күрсәтегез. Күләме 10-12 җөмлә. (15 балл)**

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 11 нче сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сораулары**

**Хөрмәтле олимпиадада катнашучы!** Сезгә олимпиаданың җиде биремен эшләргә кирәк булачак. Биремнәрне үтәү вакыты – 180 минут. Биремнәр шушы бланкларда эшләнә.
Максималь балл – **50**. Уңышлар!

**1. Нинди сәнгати алым турында сүз баруын билгеләгез. (2 балл)**

- ул әдәби әсәрдә геройларның эчке дөньясын: фикерләрен, хисләрен, кичерешләрен һәм рухи халәтләрен ачып бирүгә юнәлтелгән;
- ул авторга герое гамәленең эчке сәбәпләрен аңлату, аң һәм аң төпкеленең катлаулы эшен күрсәтергә мөмкинлек бирә;
- аның аша язучы еш кына кеше табигатенең универсаль якларын өйрәнә, яшәешнең мәңгелек сорауларына ачыклык кертә.

**Җавап:** психологизм

**2. Футуризм агымына хас булмаган 2 сыйфатны билгеләгез. (2 балл)**

а) агрессив-бунтарь шәхесне сурәтләү;

ә) тормышны хаос, тәртипсезлек рәвешендә күрсәтү;

б) кеше бизәкле һәм фаҗигалы дөнья реальлеген образлы күзаллый дип санау;

в) ямьсезлек эстетикасына йөз тоту;

г) үзәктә ялгыз шәхес концепциясе яту;

д) әдәби шартлылыктан баш тарту.

**Җавап:**

б) кеше бизәкле һәм фаҗигалы дөнья реальлеген образлы күзаллый дип санау;

г) үзәктә ялгыз шәхес концепциясе яту.

**3. Сорауларга җавап бирегез.**



**1) Портреттагы әдипнең исемен языгыз. (1 балл)**

**Җавап:** Фатих Кәрим

**2) Ул кайда туган? Дөрес җавапны билгеләгез. (1 балл)**

а) Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында

ә) Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылы

б) Оренбург губернасы Эстәрлетамак өязе Җиргән авылы

в) Татарстанның Мөслим районы Олы Чакмак авылы

**Җавап:** а) Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында

**3. Әлеге әдип турында дөреслеккә туры килмәгән фактны билгеләгез (2 балл)**

а) Ул 1925-1929 елларда Казан җир төзелеше техникумында белем ала.

ә) Шагыйрь нахак бәла күтәреп, дүрт ел төрмәдә утыра.

б) Әдип 2002 елның 13 мартында вафат була һәм Яңа бистә зиратына җирләнә.

в) 2025 елда шагыйрьгә Казанда һәйкәл ачыла.

**Җавап:** б) Әдип 2002 елның 13 мартында вафат була һәм Яңа бистә зиратына җирләнә.

**4. Колшәрифнең кайсы чор әдәбияты вәкиле булуын билгеләгез. (1 балл)**

а) Алтын Урда чоры әдәбияты.

ә) Казан ханлыгы чоры әдәбияты.

б) Торгынлык чоры әдәбияты (XVI гасырның  II яртысы – XVIII гасыр).

в) Яңарыш дәвере әдәбияты.

**Җавап**: ә) Казан ханлыгы чоры әдәбияты.

**5. Бирелгән сүзләр рәте ярдәмендә әсәрләрнең исемен, авторын һәм жанрын билгеләгез. (9 балл)**

а) Төш, йолдызлар, аждаһа, сугыш, агу, үлем, мәхдүм.

**Җавап:** К. Тинчурин. “Сүнгән йолдызлар”, драма

а) Пәке, йола, шәҗәрә, миләш агачы, Гөлйөзем әби, талак, ике каен.

**Җавап:** Г. Исхакый. “Сөннәтче бабай”, повесть

б) Кечкенә тәрәзә, миләш агачы, ак чыбылдык, ана, хат, хат ташучы, сугыш, Хәсән.

**Җавап:** Ә. Еники. “Ана һәм кыз”, хикәя

**6. Хикәядән өзекне укыгыз.**

Бүген июньнең егерме сигезенче көне... Туганы аның һәр елны шушы числоларда яки июль башларында институттан кайта торган иде. Әнисенең, туганнарының сөеп, сокланып карауларына каршы ул һаман бер сүз белән, — гүя аңардан шуны гына сорыйлар, — җавап кайтара иде:

— Әни, зачётларымны башкалардан элек биреп бетердем, сезнең янга кайтырга ашыктым.

Былтыр исә ул институтны тәмам бетереп кайтырга тиеш иде. Ләкин өйгә, туганнары янына шундый зур шатлыкның бәйрәмен бергәләп үткәрер өчен кайтасы вакытта фронтка китеп барды. Ә өйдә аның бу кайтуын көтү әле һаман аларның йөрәкләрендә саклана. Һәрхәлдә, ана бүген, моны исенә төшереп, сүз кузгатмыйча калмас.

Кечкенә өй эче яңгыр белән юылып яшәргән көннең җылы яктылыгыннан киңәйгән кебек... Миләш агачының яфраклары аша төшкән кояш нурлары, өйнең идән-стеналарын эре-эре челтәрле бизәкләр белән

чуарлап, тибрәнеп уйныйлар. Өстәлдәге графинның түгәрәк бөкесе, ачык шкафның тар шүрлегендәге киртләчләренә кыстырган балкашык башлары бу шаян, йөгерешкән нурларны үзләренә җыялар һәм үзләре дә кечкенә кояшчык шикелле тирә-юньнәренә күз камаштыргыч яктылык чәчеп балкыйлар... Куе-җиңел, хуш исле һава, өй эченә берьюлы мул булып керергә теләгәндәй, тәрәзәнең читләренә җыелган ак пәрдәне күтәреп-күтәреп куя һәм һәрнәрсәне иркәләп, сыйпап йөргән кебек тоела.

Ананың бүген кәефе яхшы. Бу шифалы һаваны сулавы аңа җиңел, рәхәт; зәгыйфь тәнендә, никадәр хәлсезләнгәнен сиздереп, ниндидер бер җылымса талгынлык йөри.

**Сорауларга җавап бирегез.**

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)**

**Җавап:** Ана һәм кыз

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)**

**Җавап:** Әмирхан Еники

**б) Өзектә сүз кемнәр турында баруын билгеләгез (1 балл). Әсәр героеның нинди хисләр кичерүен языгыз. (2 балл)**

**Җавап:** сугыштан улын көткән ана турында. Сагышлану, кайгыру, өметләнү, соклану.

**в) Өзектән**

- **метафорага мисаллар табып языгыз (1 балл)**

**Җавап:** йөрәктә саклау.

- **чагыштыруга мисаллар китерегез (4 балл)**

**Җавап:** көннең җылы яктылыгыннан киңәйгән кебек; үзләре дә кечкенә кояшчык шикелле; өй эченә берьюлы мул булып керергә теләгәндәй; һәрнәрсәне иркәләп, сыйпап йөргән кебек.

- **эпитетка мисаллар табып языгыз (7 балл)**

**Җавап:** зур шатлык, җылы яктылык; яңгыр белән юылып яшәргән көн; шаян, йөгерешкән нурлар; куе-җиңел, хуш исле һава; шифалы һава; зәгыйфь тән; җылымса талгынлык.

**7. Үзегез яратып укыган әдәби әсәрне, исемен күрсәтмичә, ләкин аны танырлык итеп характерлап языгыз. Ахырдан әсәрнең исемен, авторын күрсәтегез. Күләме 10-12 җөмлә. (15 балл)**